КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 апрель г.Казань № 535

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы турындагы нигезләмәсен һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составын раслау турында» 2021 ел, 24 май, 367 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы турындагы нигезләмәсен һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус

икътисадый зонасының эксперт советы составын раслау турында» 2021 ел, 24 май, 367 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 октябрь, 1110 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының эксперт советы составына (алга таба – совет) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

совет составыннан А.А.Новиковны, И.И.Шакировны чыгарырга;

совет составына кертергә:

Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Андрей Геннадьевич Карсаловны (килешү буенча);

Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Әхмәт улы Фәйрушинны (килешү буенча);

Владимир Петрович Пятыхның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Төбәкләрне үстерү департаменты директоры урынбасары (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин